ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19,с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район
422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт,
Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**24.06.2016 ел** **№ 15**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашу рәвешләрен билгеләү турында**

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 18 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2014 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашу рәвешләрен билгеләү максатларында Арча муниципаль районының “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, ПОСТАНОВЛЯЕТ Арча муниципаль районы “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның беренчел

янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә түбәндәгеләр катнашу рәвешләрен билгеләргә:

янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә катнашу;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә социаль әһәмиятле эшләр башкару;

эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;

алар милкендәге биналарда һәм корылмаларда янгыннарны сүндерүнең беренчел чаралары булу;

янгынны ачыклаганда алар турында кичекмәстән янгын сүндерүчегә хәбәр итәргә;

янгын сүндерү сагы килгәнче кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгынны сүндерү буенча кулдан килгәнчә чаралар күрү;

янгынны сүндергәндә янгын сагына ярдәм күрсәтү;

дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затының аларга караган җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны тикшерүләр һәм тикшерүләр уздыру һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында аларны тикшерү мөмкинлекләрен бирү.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Ташкичү авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин